**МИНИСТЕРСТВО СПОРТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПОРТ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

24.09.2024 г.Казань № 467

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының 2023 елның 21 ноябреннән 572 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы тарафыннан администрацияләнә торган түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өмет юк дип тану турында карар кабул итү Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертүгә бәйле рәвештә

**боерам**:

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының 2023 елның 21 ноябреннән 572 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы тарафыннан администрацияләнә торган түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өмет юк дип тану турында карар кабул итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. 2002 елның 26 октябреннән 127-ФЗ номерлы «Бөлгенлек (банкротлык) турында» федераль закон нигезендә гражданның, индивидуаль эшкуарның банкротлык процедурасын тәмамлау – бюджетка түләүләр буенча бурыч өлешендә, күрсәтелгән федераль закон нигезендә аны түләү йөкләмәләрне үтәүдән азат ителде;»;

2.3 пунктчасын гамәлдән чыккан дип таныргa;

2.5 пунктчасын  түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.5. Штраф яисә суд тарафыннан Министрлык бюджетка түләүләр буенча бурычларны, шул исәптән аны түләтүнең билгеләнгән срогы чыгуга бәйле рәвештә, түләтү мөмкинлеген югалта торган карар кабул итү рәвешендә җәзага тартылганнарга карата амнистия яисә кичерү турында актлар куллану;»;

2.6 пунктчасын  түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6. әгәр күләме банкротлык турындагы эш буенча производство ачу өчен Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән бурычка куелган таләпләр күләменнән артмаган бурыч барлыкка килгән көннән алып биш елдан артык вакыт үтсә, 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы «Суд карарын тормышка ашыру турында» федераль законның 46 маддәсендәге 1 өлешнең 3 яки 4 пунктында каралган нигез буенча башкарма документны гариза бирүчегә кире кайтарганда,суд приставы-башкаручы тарафыннан башкару производствосы тәмамлану турында карар чыгару;»;

түбәндәге эчтәлектәге $2.6^{1}$ пунктчасы белән тулыландырырга:

«$2.6^{1}$ банкротлык турындагы эштә кулланыла торган процедураларны үткәрүгә суд чыгымнарын каплау өчен җитәрлек акчалар булмау сәбәпле, бурычлыны банкрот дип тану яисә банкротлык турында эш буенча эшне туктату турында гаризаны кире кайтару турында суд тарафыннан акт кабул итү;»;

дүртенче абзацта «2.3 пунктчасында» сүзләрен «2.2 пунктчасында» сүзләре белән алмаштырырга;

җиденче абзацта «2.6 пунктчасында» сүзләрен «2.6, $2.6^{1}$ пунктчаларында» сүзләре белән алмаштырырга»;

сигезенче абзацта «2.6 пунктчасының өченче абзацында» сүзләрен «$2.6^{1}$ пунктчасында» сүзләре белән алмаштырырга;

тәртипне түбәндәге эчтәлекле $9^{1}$ пунктчасы белән тулыландырырга:

«$9^{1}$. Комиссия тапшырылган документлар нигезендә Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турындагы мәсьәләне документлар Комиссиягә кергән көннән алып унбиш эш көне эчендә карый.»;

Тәртипкә түбәндәге эчтәлекле $10^1$ пунктча өстәргә:

«$10^1$. Комиссия утырышы йомгаклары буенча, тәртипнең 10 пунктындагы өченче абзацында күрсәтелгән очракта, утырыш уздырылган көннән алып ун эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында карар проекты әзерләнә.»;

түбәндәге эчтәлекле 12 пункт белән тулыландырырга:

«12. Тәртипнең 10 пунктының дүртенче абзацында күрсәтелгән очракта, Комиссия утырышы беркетмәсендә Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану өчен нигезләр булмау турындагы мәгълүмат чагылдырыла. Беркетмә утырышта рәислек итүче һәм комиссия секретаре тарафыннан имзалана һәм хәбәр итү өчен министрга җибәрелә.».

Министр В.А.Леонов